СОВЕТ
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ
ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: Mcel.Drz@tatar.ru,

---

РЕШЕНИЕ с.Малая Цильна КАРАР

18 декабрь 2023 ел №36/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирле Советының 2023 елнын 25 маендагы 30/3 номерлы (2023 елның 27 июлендәге 31/1 редакциясендә) карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 11 пунктта** икенче җөмләне төшереп калдырырга**;**

**2) 17 пунктны** үз көчен югалткан дип танырга**;**

**3) 20 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:**

«20. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган класслы чин бирү турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Глава Малоцильнинского
сельского поселения: Г.Ш.Халитов